КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 26 февраль г.Казань № 103

Казан шәһәре, Адамюк урамы, 4 йорт адресы буенча бинаның фасадында мемориаль такта кую турында

Совет хәрби башлыгы, генерал-майор Красавин Фёдор Михайловичның истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Казан шәһәре, Адамюк урамы, 4 нче йорт адресы буенча ул яшәгән бинаның фасадына татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән Ф.М.Красавинга мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта 1945 – 1948 елларда генерал-майор,
Казан гарнизоны начальнигы,
Бөек Ватан сугышы елларында
1945 елның 27 гыйнварында
Аушвиц-Биркенау (Освенцим)
үлем лагерен азат иткән
100 нче укчы дивизия командиры
Фёдор Михайлович Красавин яшәде

___

В этом доме в 1945 – 1948 гг.
жил генерал-майор, начальник Казанского гарнизона,
в годы Великой Отечественной войны
командир 100-й стрелковой дивизии,
освободившей 27 января 1945 г.
лагерь смерти Аушвиц-Биркенау (Освенцим),
Фёдор Михайлович Красавин».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин